РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ГОРОДА АЛЬМЕТЬЕВСКА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘЛМӘТ ШӘҺӘРЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«21» март 2019 ел . Әлмәт шәһәре №30

Җир кишәрлеген шартлы рәвештә
файдалануга рөхсәт бирү турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 39 маддасе, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон 14, 15 маддәсе, Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Советының 2009 елның 25 декабрендәге 366 номерлы карары белән расланган «Әлмәт шәһәре» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре нигезендә, Россия Федерациясе Икътисадый үсеш министрлыгының «Җир кишәрлекләреннән рөхсәт ителгән файдалану төрләре классификаторын раслау турында» 2015 елның 30 сентябрендәге 709 номерлы боерыгы, Әлмәт шәһәре башлыгының 2019 елның 21 февралендәге 07 номерлы «Җәмәгать тыңлауларын билгеләү турында»гы карары нигезендә,

БАШКАРМА КОМИТЕТЫ КАРАР БИРӘ:

1. Җир кишәрлеген файдалануның шартлы рөхсәт ителгән төренә Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Әлмәт шәһәре, Габдулла Тукай проспекты, 14 йорт адресы буенча, кадастр номеры 16:45:010106:6 булган җир участогына - "конфессиональ объектлар", җир кишәрлекләреннән рөхсәт ителгән файдалану төрләре классификаторы буенча код 3.7 - "дини файдалану" рөхсәт бирергә.
2. «Әлмәт муниципаль районының архитектура һәм шәһәр төзелеше идарәсе» муниципаль бюджет учреждениесенә (Р.Р. Мордагулова) Җир-кадастр документларына тиешле үзгәрешләр кертү өчен «Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Федераль кадастр палатасы» федераль дәүләт бюджет учреждениесенең Татарстан Республикасы буенча филиалына (Мозаффарова Л. А.) җибәрергә.
3. Район башкарма комитетының хокук идарәсенә (Ханнанова Ә.Б.) әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталына (PRAVO.TATARSTAN.RU) урнаштырырга.
4. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны төзелеш буенча башкарма комитет җитәкчесе урынбасары А.А. Мөхәммәтҗанова йөкләргә.

Шәһәр Башкарма комитеты җитәкчесе Л.Ф. Валеев